ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 31 һәм 150 статьяларына наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше өчен җаваплылыкны катгыйландыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 31 һәм 150 статьяларына наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше өчен җаваплылыкны катгыйландыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

2. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 31 һәм 150 статьяларына наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше өчен җаваплылыкны катгыйландыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын рәсми бәяләмәләр алу өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенә һәм Россия Федерациясе Югары Судына җибәрергә.

3. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 31 һәм 150 статьяларына наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше өчен җаваплылыкны катгыйландыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Хөкүмәтеннән һәм Россия Федерациясе Югары Судыннан рәсми бәяләмәләр алганнан соң Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

4. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына сайланган депутатларга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

5. Күрсәтелгән закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан рәсми вәкил итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 11 июне
№ 972-VI ДС